ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06 апрель 2023 ел. № 2734

Башкарма комитетның 2022 елның 11 октябрендәге 5459 номерлы карары белән расланган юл билгеләрендә индивидуаль проектлауның мәгълүмат билгеләрен урнаштыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә юл хәрәкәтен оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 443-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Мунципаль хокукый актлар турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 11 октябрендәге 5459 номерлы карары белән расланган юл билгеләрендә индивидуаль проектлауның мәгълүмат билгеләрен урнаштыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2.1. Муниципаль хезмәттән файдалану хокукына ия затлар булып физик һәм юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр – автомобиль юлларыннан файдаланучылар (алга таба – гариза бирүче) тора.»;

2) 1.5.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5.2. Әлеге административ регламентта файдаланылган төп төшенчәләр «Россия Федерациясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закондагы, «Россия Федерациясендә юл хәрәкәтен оештыру турында һәм Россия Федерациясенең

аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 443-ФЗ номерлы Федераль закондагы кебек үк мәгънәдә кулланыла.»;

3) түбәндәге эчтәлектәге 1.5.3 пункт өстәргә:

«1.5.3. Административ регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) 2 статьясының 3 пункты нигезендә бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос аңлашыла.»;

4) 2.3.1 пунктның 3 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

5) 2.4.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Муниципаль хезмәт биш эш көне эчендә күрсәтелә.»;

6) 2.5.1 пунктта:

- 1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе гражданының паспорты яисә Россия Федерациясе законы нигезендә шәхесне раслаучы башка документ;»;

- 3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) гариза:

- кәгазь документ формасында (әлеге административ регламентка 4 нче кушымта);

- Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, административ регламентның 2.5.3 пункты таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада (тиешле мәгълүматларны гаризаның электрон формасына кертү юлы белән тутырыла);»;

7) 2.5.3 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5.3. Бердәм портал, Республика порталы аша җибәрелгәндә, гариза гариза бирүченең гади электрон имзасы белән имзалана.»;

8) 2.7.1 пунктта:

- 5 пунктчада «гаризаны» сүзеннән соң «Бердәм порталда,» сүзләрен өстәргә;

- түбәндәге эчтәлектәге 9 пунктча өстәргә:

«9) гариза гариза бирүченең мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтләре булмаган зат тарафыннан бирелгән;»;

9) 2.7.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7.3. Гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар (административ регламентка 3 нче кушымта) гариза бирүчене кабул итү вакытында да, Органның җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлектән файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны (мәгълүматларны) алганнан соң да, гаризаны теркәгән көннән башлап 9 эш көненнән артмаган срокта кабул ителергә мөмкин.»;

10) 2.8.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге:

1) гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документлар әлеге Регламентта билгеләнгән таләпләргә туры килмәү;

2) гариза бирүченең муниципаль хезмәтән файдалануга хокукы булмау;

3) гариза бирүче инициативасы буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә гаризаны кире алу;

4) урнаштырылачак индивидуаль проектлауның мәгълүмат билгесе ГОСТ Р-52289-2019, ГОСТ Р-52290-2004 таләпләренә туры килми;

5) индивидуаль проектлауның мәгълүмат билгесе урнаштырылган урын Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенә карамый.»;

11) 2.8.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза Бердәм порталда, Республика порталында, шулай ук муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында бастырып чыгарылган муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту тыела.»;

12) 2.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтләнгән экспертлар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеге

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.»;

13) 2.14.1, 2.14.2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.14.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.

Гариза бирүчеләрне кабул итү урыннары документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу һәм алар чикләрендә хәрәкәтләнү).

Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

2.14.2. Инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү максатларында тәэмин ителә:

1) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе бозылган инвалидларны озатып йөрү һәм аларга ярдәм күрсәтү;

2) транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып;

3) аларның яшәеш мөмкинлекләре чикле булуны исәпкә алып, инвалидларның хезмәтләрдән тоткарлыксыз файдалануын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөрткечләрне тиешенчә урнаштыру;

4) ишетә һәм күрә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны рельефлы-нокталы Брайль шрифтында башкарылган билгеләр белән кабатлау;

5) сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

6) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Юл күрсәтүче этне махсус өйрәтүне раслый торган документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н боерыгы белән билгеләнгән форма буенча һәм тәртиптә бирелә һәм махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булганда, юл күрсәтүче этне кертү.»;

14) 3.2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.3. Гариза бирүче Органга телефон һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә, шулай ук Бердәм порталда, Республика порталында, Орган сайтында муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары, шул исәптән тапшырыла торган документлар составы, формасы һәм муниципаль хезмәттән файдалану өчен башка мәсьәләләр буенча консультация алырга хокуклы.

Консультация бирү өчен җаваплы вазыйфаи зат административ регламентның 1.3.4 пункты таләпләре нигезендә гариза бирүчегә хәбәр итә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар мөрәҗәгать кергән көннән башлап өч эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәсе булып тора: тапшырыла торган документлар составы, формасы һәм муниципаль хезмәттән файдалану өчен кирәкле башка мәсьәләләр буенча консультацияләр.»;

15) 3.3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.2. Бердәм портал, Республика порталы аша электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү өчен документлар кабул итү.»;

16) 3.3.2.1 пунктның 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гаризаны формат-логик тикшерү бердәм портал тарафыннан орган билгеләгән таләпләр нигезендә автомат рәвештә, гариза бирүче тарафыннан гаризаның электрон формасының һәр кырын тутыру барышында гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан гаризаның электрон формасындагы дөрес тутырылмаган кыр ачыкланганда, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны мәгълүмати хәбәр юлы белән бетерү тәртибе турында гаризаның электрон формасында ук хәбәр ителә.»;

17) 3.3.3.3 пунктның икенче, бишенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«эшләр номенклатурасы нигезендә гаризага номер бирә;»;

«Бердәм порталга, Республика порталына мөрәҗәгать итү юлы белән, электрон имзаның чын булу шартлары үтәлешен тикшерә (гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалифицияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар тапшырылган очракта).»;

18) 3.4.2 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар гариза кергән көннән башлап ике эш көне эчендә башкарыла.»;

19) 3.4.3 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар гариза кергән көннән башлап бер эш көне эчендә башкарыла.»;

20) 3.4.4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Административ регламентның 3.4 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны башкаруның максималь срогы гариза кергән көннән башлап өч эш көне тәшкил итә.»;

21) 3.5.3.2 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Административ процедураларны башкару нәтиҗәсе булып тора: Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып, гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүне (шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тартуны) раслаучы документ җибәрү (бирү).»;

22) 3.6.3 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Административ процедураларны башкару нәтиҗәсе булып тора: техник

хатасын төзәтеп, гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.»;

23) түбәндәге эчтәлектәге 3.7 пункт өстәргә:

«3.7. Гариза бирүчеләрнең гомуми билгеләр белән, шул исәптән алар мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт нәтиҗәләренә карата да берләшкән аерым категорияләренә муниципаль хезмәт күрсәтү;

Муниципаль хезмәт гариза бирүченең категориясенә һәм мөрәҗәгать итү нигезенә карамастан күрсәтелә.»;

24) 4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Контроль тикшерүләр планлы (җирле үзидарә органнарының ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырылырга) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр үткәргәндә муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле барлык мәсьәләләр (комплекслы тикшерүләр) яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча каралырга мөмкин.»;

25) 4.2.1 - 4.2.4 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

26) 4 нче кушымтаны кушымтада каралган редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2023 елның 6 апрелендәге
2734 номерлы карарына
кушымта

Юл билгеләрендә индивидуаль проектлауның мәгълүмат билгеләрен урнаштыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
4 нче кушымта

Форма

Кемгә
________________________________
(җирле үзидарә органының исеме)
______________________________________
______________________________________
электрон почта адресы___________________

__________________________________________________________________участогында
(биналарга, корылмаларга бәйләп, автоюлның км күрсәтелә)

__________________________________________________________________________,
(урам исеме)

юл билгеләрендә индивидуаль проектлауның мәгълүмат билгеләрен урнаштыруны килештерүне сорыйм.
Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:
Индивидуаль проектлауның мәгълүмат билгесен күрсәтеп, индивидуаль проектлауның мәгълүмат билгесе дислокациясе схемасы
________________________________________
________________________________________

Индивидуаль проектлау билгесен эксплуатацияләүнең барлык чорында аңа техник хезмәт күрсәтергә һәм авария-торгызу эшләрен башкарырга йөкләмә алам.

«____»__________20_____ел

________________
(имза)

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирүне сорыйм:

☐ Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетына, Бердәм порталның шәхси кабинетына;

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәккә;

☐ Органда.

«____» ________________ 20__ ел _________________ ______________________

(дата) (имза) (Ф.И.А.и.)

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева